ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2021 г.Лениногорск № 1269

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1206 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1206 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә эшләүчеләрнең хезмәт хакының база окладларын билгеләү

1. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персоналның һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку бүлеге секретаре | 13 617 | 13 890 | - |
| Педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инспектор | - | 14 480 | 16 700 |
| | Физик культура буенча инспектор | | | |
| | Музыкаль җитәкче | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тренер-укытучы | - | 14 487 | 16 720 |
| | Концертмейстер | | | |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | | | |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | Педагог-оештыручы | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| | Инструктор-методист | - | - | 16 720 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Производство укыту остасы | - | 14 493 | 16 732 |
| | Педагог-психолог | | | |
| | Методист | - | - | 16 732 |
| | Өстәмә белем бирү өлкән педагогы | | | |
| | Өлкән тренер-укытучы | | | |
| | Өлкән инструктор-методист | | | |
| Дүртенче | Укытучы (профессор- | - | 14 495 | 16 736 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| квалификация дәрәҗәсе | укытучылар составына кертелгән укытучы вазыйфасыннан тыш) | | | |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | | | |
| | Өлкән методист | - | - | 16 736 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Бүлек мөдире (начальнигы) структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту | - | - | 16 801 |

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы башка структур бүлекчәләр | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерым структур бүлекчә мөдире (начальнигы) | - | - | 16 864 |

2. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми | квалификацияле эшчеләр, | аттестацияне уңышлы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | белем, урта гомуми белем | хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Икенче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринар фельдшер | - | 15 193 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация) | | | |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | - | - | 15 749 |
| | Зоотехник | | | |
| | Ветеринар табиб | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле агроном | - | - | 15 804 |
| | II категорияле зоотехник | | | |
| | II категорияле ветеринар | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | табиб | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | - | - | 15 859 |
| | I категорияле зоотехник | | | |
| | I категорияле ветеринар табиб | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәп баручы агроном | - | - | 15 914 |
| | Әйдәп баручы зоотехник | | | |
| | Әйдәп баручы ветеринар табиб | | | |
| Өченче дәрәҗәдәге авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | - | - | 16 640 |

3. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә медицина хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Аена база окладлы күләме, сумнарда |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 16 237 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы <*> | 17 937 |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазыйфаларының профессиональ квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә караган табиб-белгечләрдән тыш) | 19 437 |
| --------------------------------<br><*> Вазыйфа оешмада өч һәм аннан күбрәк шәфкать туташы булганда билгеләнә. | | |

4. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә мәдәният хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Аена база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч»квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары»  һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 14 726 | 15 237 | 15 537 |
| Костюмер мөдире | | | |
| Мәдәни оештыручы | | | |
| «Әйдәп баручы звеноның мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Библиограф | 14 726 | 15 737 | 18 237 |
| Китапханәче | | | |
| Әйдәп баручы китапханәче | | | |
| Тавыш операторы | | | |
| Фондларны саклаучы | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Рәссам-скульптор | | | |
| Рәссам-куючы | | | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | - | 16 937 | 19 537"; |
| Китапханәнең бүлек (секторы) мөдире | | | |
| Кино һәм видеофильмнарны прокатка бирү бүлеге мөдире | | | |
| Тавыш режиссеры | | | |
| Режиссер-куючы | | | |
| Сәнгать җитәкчесе | | | |

VII бүлектә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары белән эшләрдә мәшгуль хезмәткәрләргә, шулай ук нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш эштә, төнге вакытта һәм нормаль эштән читләшкән башка шартларда эшләр башкарганда эш өчен компенсация характерындагы түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kh} = \left( O_b \times \frac{H_{fk}}{H_N} + P \right) \times D_{kh},$$

кайда:

$B_{kh}$ - компенсация характерындагы түләү;

$O_b$ - өстәмә белем бирү учреждениесе хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең II бүлеге нигезендә кабул ителә торган база оклады күләме;

$H_{fk}$ - аның буенча компенсация характерындагы түләү каралган фактта эшләнгән вакыт;

$H_N$ - әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады (хезмәт хакы ставкасы) өчен сәгать нормасы;

P - китап басу продукциясе һәм вакытлы басмалар белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендә компенсация педагогик хезмәткәрләргә укыту йөкләнешенә пропорциональ рәвештә билгеләнә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан да артмый.;

$D_{kh}$ - компенсация характерындагы түләүгә Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә торган өстәмә күләме.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Зарарлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүдә мәшгуль хезмәткәрләрнең хезмәт хакы, хезмәт шартлары нормаль булган төрле эш төрләре өчен билгеләнгән хезмәт хакы белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, база (вазыйфаи) окладының 4 проценты күләмендә билгеләнә.»;

VIII бүлекнең 15 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 нче таблица

Өстәмә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең башкарыла торган эшләр сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләме

| Җитәкченең хезмәт хакы буенча төркеме | Күләмле күрсәткечнең әһәмияте (уку елы башына дәүләт биреме нигезендә укучылар саны), кеше | База оклады, сумнарда | Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 1 - 200 | 22 000 | 1 000 |
| 2 | 201 - 400 | 24 000 | 2 000 |
| 3 | 401 - 700 | 28 000 | 2 000 |
| 4 | 701 - 1 200 | 29 000 | 3 000 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 32 000 | 4 000 |
| 6 | 1 801 и выше | 34 000 | 5 000»; |

5. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

В.С.Санатуллин
5-17-72